Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ № 20

2019 ел 19 июнь

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» №131-ФЗ, 1996 елның 12 январендәге «Җирләү һәм җирләү эше турында» №8-ФЗ федераль законнар нигезендә, 2007 елның 18 маендагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» №196 карары нигезендә, Дәүләт учреждениесе – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасың Әлмәт шәһәрендәге идарәсе белән (районара) килешеп

Ямаш авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 2019 елның 1 июленнән 5 946,47 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Ямаш авылы, Совет урамы, 109а йорты; Зәй-Чишмә авылы, Верхняя урамы, 186 нчы йорт; Березовка авылы, Үзәк урам, 10 нчы йорт территоиясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты "Интернет" челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2019 елның 1 июленнән үз кеченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны үз артымда калдырам.

Ямаш авылы
башкарма комитеты җитәкчесе А.И. Чуркин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы башкарма
комитетының 2019 елның
19 июнендәге № 20
карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Күмү өчөн кирәкле документларны рәсмиләштерү | 84,25 |
| 2 | Гробны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне тапшыру | 3 414,27 |
| 3 | Мәрхүмнең гәүдәсен (мәетен ) зиратка алып бару | 530,44 |
| 4 | Кабер (казу һәм күмү) | 1 917,51 |
| | Барлыгы | 5 946,47 |

Ямаш авылы
башкарма комитеты җитәкчесе А.И. Чуркин

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы башкарма
комитетының 2019 елның
19 июнендәге № 20
карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Ямаш авылы җирлегендә җирләү хезмәтләренең гарантияләнгән исемлеге
нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| №№ п/п | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 84,25 |
| 2 | Мәетне кәфенгә терү | 2 001,70 |
| 3 | Гробны һәм күмү өчен кирәкле башка әйберләрне тапшыру | 1 412,58 |
| 4 | Мәрхүмнең гәүдәсен ( мәетен ) зиратка алып бару | 530,44 |
| 5 | Кабер (казу һәм күмү) | 1 917,50 |
| | Барлыгы | 5 946,47 |

Ямаш авылы
башкарма комитеты җитәкчесе А.И. Чуркин